| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» 12 2025ел № 342

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәдәният оешмалары тарафыннан гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен килештерү, аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт булган сәхнә әйберләрен арендага бирү яисә түләүсез файдалануга тапшыру Тәртибен раслау турында**

2006 елның 26 июлендәге «Конкуренцияне яклау турында» 135–ФЗ номерлы Федераль законның $17^1$ статьясының $3^6$ өлешенә яраштырып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 24 сентябрендәге 1610 номерлы карары белән расланган театр-тамаша, мәдәни-агарту яисә тамаша-күңел ачу чараларында спектакльнең (тамашаның) сәхнә бизәлешенә яисә стационар сәхнә җиһазына караган һәм оператив идарә итү хокукында дәүләт яисә муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне, әлеге мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәләре, аренда шартнамәләре яисә аукционнар үткәрмичә генә файдалану кагыйдәләренең 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач муниципаль районы мәдәният оешмалары тарафыннан мөлкәт милекчесе һәм гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган орган белән килештерү, аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт булган сәхнә әйберләрен арендага бирү яисә түләүсез файдалануга тапшыру тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгына йөкләргә.

Житәкче А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
20 25 елның « 15 » 12
342 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәдәният оешмалары тарафыннан гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен килештерү, аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт булган сәхнә әйберләрен арендага бирү яисә түләүсез файдалануга тапшыру Тәртибе

1. Әлеге Тәртип, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының мәдәният оешмалары (алга таба – мәдәният оешмалары) мөлкәт милекчесе һәм гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган белән спектакльнең (тамашаның) сәхнә бизәлешенә яки стационар сәхнә җиһазларына караган һәм мәдәният оешмаларына оператив идарә итү хокукында беркетелгән аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне (алга таба – аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт) театр тамашасында яки тамаша-күңел ачу чараларында куллану өчен, әлеге мөлкәтне, конкурслар яки аукционнар үткәрмичә генә арендага, бушлай файдалануга тапшыруның килештерү процедурасын билгели.

2. Мәдәният оешмалары тарафыннан аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә карата аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен төзү «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның $17^1$ статьясындагы $3^6$ өлеше нигезендә конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә генә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә карата спектакльне сәхнә бизәлешенә (тәкъдим итүгә) яисә стационар сәхнә җиһазларына караган һәм дәүләт яисә муниципаль мәдәният оешмаларына оператив идарә итү хокукында беркетелгән күрсәтелгән мөлкәтне театр-тамаша, мәдәни-агарту яисә тамаша-күңел ачу чараларында һәм күрсәтелгән мөлкәт төрләре исемлегендә файдалану өчен аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен уздырмыйча төзү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 24 сентябрендәге 1610 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә, шартларында һәм спектакльнең сәхнә бизәлешенә яисә стационар сәхнә җиһазларына карый торган мөлкәт төрләре исемлегенә туры китереп гамәлгә ашырыла.

3. Мәдәният оешмасы, юридик зат яки шәхси зат, шул исәптән шәхси эшмәкәр буларак теркәлгән зат (алга таба – хуҗалык субъекты) тарафыннан аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә килешү төзү турында гариза кергән көннән башлап 5 эш көне эчендә, хуҗалык субъектына аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага яки бушлай файдалануга тапшыруны килештерү турында мөрәҗәгатьне язмача рәвештә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына җибәрергә тиеш.

4. Мөрәҗәгатьтә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) хуҗалык субъектының исеме, урнашкан урыны турында белешмәләр, почта адресы, контакт телефоны номеры;

2) арендага, бушлай файдалануга тапшырырга тәкъдим ителгән аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт турында белешмәләр (исеме, инвентарь номеры (булган очракта), баланс бәясе, техник характеристикалары һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне индивидуальләштерергә мөмкинлек бирүче башка мәгълүматлар);

3) аренда килешүен, түләүсез файдалану килешүен төзү тәкъдим ителгән вакыт, аренда түләве күләме;

4) хуҗалык итүче субъект аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт кулланырга планлаштырган театр-тамаша, мәдәни-агарту яки тамаша-күңел ачу чаралары турында белешмәләр.

5. Мөрәҗәгатькә түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) хуҗалык итүче субъектның аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә карата килешү төзү ниятен белдергән гариза күчермәсе;

2) хуҗалык итүче субъект физик зат булса, физик затның шәхесен раслый торган документның күчермәсе;

3) шәхесне раслый торган документның күчермәсе һәм гариза җибәрү датасына шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан бер ай кала алынган өземтә – шәхси эшмәкәрләр өчен;

4) гариза җибәрү датасына кадәр юридик затлар тарафыннан бер ай эчендә алынган Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә – юридик затлар өчен;

5) аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага бирү яки бушлай файдалану килешүе проекты;

6) бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән аренда түләвенең базар бәясен бәяләү турында хисап (тапшыру датасына 30 көннән дә артык булмаган вакыт аралыгы белән);

7) хуҗалык итүче субъектның мәдәният оешмасы белән элек төзелгән килешүләр буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булу (булмау) турында белешмә.

6. Мәдәният оешмасына бер үк аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә карата ике һәм аннан күбрәк хуҗалык субъектыннан гаризалар кергән очракта, мөрәҗәгатьләр гаризаларның килү датасыннан чыгып, чират тәртибендә җибәрелә.

7. Мөрәҗәгатьне һәм аңа кушып бирелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча аны теркәү көненнән 10 көн эчендә түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага яки бушлай файдалануга тапшыруны килештерү;

2) аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага яки бушлай файдалануга тапшыруны килештерүдән баш тарту.

8. Аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага яки бушлай файдалануга тапшыруны килештерүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

1) әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларындагы тапшырылган белешмәләрдә һәм документларда дөрес булмаган мәгълүмат булу;

2) хуҗалык итүче субъектның аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне кулланырга планлаштырган чараларның театр-тамаша, мәдәни-агарту яки тамаша-күңел ачу чараларына туры килмәве;

3) хуҗалык итүче субъектның мәдәният оешмасы белән элек төзелгән килешүләр буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булу.

9. Кабул ителгән карар милекче тарафыннан Балтач муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының муниципаль хокукый акты формасында һәм гамәлгә куючы тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының муниципаль хокукый акты формасында рәсмиләштерелә һәм кабул ителгән көннән башлап 3 көн эчендә мәдәният оешмасына җибәрелә.

10. Аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага, бушлай файдалануга тапшыруны килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә мөрәҗәгать һәм аңа кушылган документлар, әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 3 көн эчендә мәдәният оешмасына кире кайтарыла.

11. Аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага, бушлай файдалануга тапшыруны килештерү турында кабул ителгән карар, мәдәният оешмасы тарафыннан аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә карата конкурслар яки аукционнар үткәрмичә аренда килешүе, бушлай файдалану килешүе төзү өчен нигез булып тора.